+СОВЕТ ШИШИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШЕҢШЕҢӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ
31.10.2022 ел

КАРАР
№ 53

«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Шеңшеңәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 25нче декабрендәге 98 номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында (2019 елның 30 апрелендәге 105 номерлы, 2020 елның 18 декабрендәге 16 номерлы үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясына туры китереп, «Территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 19 июлендәге 01-16/5057 номерлы Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Шеңшеңәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә тулаем алганда төзекләндерү объектларын чиста һәм тәртиптә тотуга бердәм таләпләр билгеләү максатларында, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Шеңшеңәр авыл җирлеге Советының 2018 елның 25 нче декабрендәге 98 номерлы(2019 елның 30 апрелендәге 105 номерлы, 2020 елның 18 декабрендәге 16 номерлы үзгәрешләр белән) карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 статьяның «Җирлек территориясен санитар чистарту» 3.1 пунктында (шәхси йорт биләмәләре территорияләрендә, предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр территорияләрендә) сүзтезмәләреннән соң «юл сервисы объектлары» сүзтезмәсен өстәргә;

1.2. 16 статьяны «Кагыйдәләрне үтәүне контрольдә тоту» 17 статья дип санарга;

1.2.1. 16 статьяның «Кагыйдәләрне үтәүне контрольдә тоту» 16.1 пунктын 17.1 пункт дип санарга;

1.2.2. 16 статьяның «Кагыйдәләрне үтәүне контрольдә тоту» 16.2 пунктын 17.2 пункт дип санарга;

1.2.3. 16 статьяның «Кагыйдәләрне үтәүне контрольдә тоту» 16.3 пунктын 17.3 пункт дип санарга;

1.3. Түбәндәге эчтәлекле 16 статья өстәргә:

«16 статья. Сервис объектларын карап тоту:

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Балтач муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар җирлекнең мәгълүмат стендында халыкка җиткергән (бастырып чыгарган) һәм Балтач муниципаль районының http://baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырган мизгелдән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Шеңшеңәр авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Салихҗанов